КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь г.Казань № 1141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы; 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы; 2021 ел, 12 февраль, 73 нче; 2022 ел, 20 июнь, 591 нче; 2022 ел, 24 ноябрь, 1260 нчы; 2023 ел, 10 февраль, 127 нче; 2023 ел, 1 июнь, 667 нче; 2023 ел, 7 октябрь, 1260 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «саклап калу» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүдә булышлык

күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта «саклап калу» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин